**СОВЕТ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
ул. Советская, д.80,
с. Новошешминск,423190

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ**
Совет урамы, 80,
Яңа Чишмә авылы, 423190

тел.: (8-84348) 2-31-00, факс: (8-84348) 2-20-22, chishma@tatar.ru

Татарстан Республикасы
Чишмә муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

2025 елның 18 июленнән

№ 58-446

Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турында нигезләмәне раслау хакында» 2021 елның 24 ноябрендәге 15-110 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, «Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2021 елның 24 ноябрендәге 15-110 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Башкарма комитеты турындагы Нигезләмәгә (Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының 2023 елның 20 апрелендәге 33-260 номерлы, 2023 елның 14 декабрендәге 39-319 номерлы, 2024 елның 27 декабрендәге 51-398 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) (алга таба - Нигезләмә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Нигезләмәнең 3.2 пунктындагы 12 пунктчасында «Татарстан Республикасы хакимияте» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә;

1.2. Нигезләмәнең 4 өлешендәге 4.1 пунктындагы 6 пунктчасында «Татарстан Республикасы хакимияте» сүзләреннән соң «муниципаль мәгариф оешмаларында спорт әзерлегенең өстәмә белем бирү программалары буенча өлкәннәргә өстәмә белем бирүне оештыру,» сүзләрен өстәргә;

1.3. Нигезләмәнең 8 өлешендәге 8.1 пунктындагы 4 пунктчаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4) район Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарларын, Башкарма комитетның тармак (функциональ) органнары җитәкчеләрен билгеләп куя һәм вазыйфаларыннан азат итә, алар арасындагы вазыйфаларны бүлешә, муниципаль хезмәткәрләрне һәм Башкарма комитетның башка хезмәткәрләрен вазыйфаларыннан азат итә, аларның эшчәнлеген тикшереп тора, аларга муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы белән алдан килештереп, бүләкләү һәм түләтү чараларын (устав нигезендә) куллана;».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда: https//pravo.tatarstan.ru, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге

Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталында Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында: https/novosheshminsk.tatarstan.ru бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тоту Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм җирлекләрнең вәкиллекле органнары белән хезмәттәшлек буенча даими комиссиясенә йөкләнә.

Яңа Чишмә муниципаль районы Башлыгы урынбасары Н.И. Попкова